КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 41

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын үткәрүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын уздыру кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 1654 номерлы карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә төбәк һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын үткәрүне оештыру турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә гадәттән тыш хәлләр килеп чыу очракларына эвакуация чараларын планлаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына әлеге чараларны планлаштыруны тәкъдим итәргә.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр

барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 5 февраль, 58 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 5 февраль, 58 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 ел, 10 июнь, 544 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 11 июль, 810 нчы карарының 6 пункты.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 24 гыйнвар, 41 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын үткәрүне оештыру турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә төбәк һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын (алга таба – гадәттән тыш хәлләр, эвакуация чаралары) үткәрүне оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. Әлеге Нигезләмәдә эвакуация чаралары дигәндә Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны (алга таба – халык), матди һәм мәдәни кыйммәтләрне гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы янаган Татарстан Республикасы территориясеннән яки гадәттән тыш хәл зонасыннан гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлы факторлары тәэсиреннән читтә урнашкан районга (урынга) (алга таба – имин район (урын)) күчерү гамәлләре аңлашыла.

Эвакуация чараларын үткәрү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы янаганда яки килеп чыкканда эвакуация чараларын үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 1654 номерлы карарында билгеләнгән максатларда гамәлгә ашырыла.

3. Эвакуация чаралары һәм аларны үткәргәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре Татарстан Республикасының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планында (алга таба – План) чагылдырыла.

План Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан эшләнә һәм раслана.

План түбәндәге мәсьәләләр буенча чараларны үз эченә ала:

1) эвакуация маршрутларын, халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарда (урыннарда) урнаштыру урыннарын планлаштыру һәм әзерләү;

2) эвакуация чараларын үткәрү өчен транспорт чараларын куллану;

3) эвакуация чараларын үткәргәндә һәм имин районнарда (урыннарда) җәмәгать тәртибен саклауны һәм гадәттән тыш хәлләр зоналарында халык мөлкәтен саклауны тәэмин итү;

4) халыкка һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр барышы турында мәгълүмат бирү;

5) эвакуация чараларын үткәргәндә республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек итү;

6) гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы яки гадәттән тыш хәл бетерелгәннән соң халыкны даими яшәү урыннарына, шулай ук матди һәм мәдәни кыйммәтләрне даими саклау урыннарына кире кайтаруны тәэмин итү.

4. Татарстан Республикасы территориясында эвакуация чаралары Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карарлары нигезендә үткәрелә.

5. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе, кичекмәстән карар таләп ителә торган очракларда, эвакуация чараларын үткәрү турында карар кабул итүче вазыйфаи затларны билгели, аннан соң Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында карар кабул ителә.

6. Халыкны имин районнан (урыннан) даими яшәү урыннарына кире кайтару Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары буенча гадәттән тыш хәлне бетерү яки кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янауны бетерү эшләре тәмамланганнан соң башкарыла.